ГЛАВА
МАЙНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАЙНА АВЫЛ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2021 с. Верх.Тат.Майна № 10

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлегенең Чуаш Майнасы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәсендәге 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктлары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 октябрендәге 99 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2.5 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлегенең Чуаш Майнасы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 18 ноябренә 14:00 сәгатькә билгеләргә.

Җыенны үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан АМЙ бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Чуаш Майнасы ав., Мәктәп ур., 10 й.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Майна авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына

ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларга вак таш җәю;
- җирлек эчендәге юлларны карап тоту (кардан чистарту);
- янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру;
- су башнясы өчен су насосы сатып алу;
- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту (урам фонарьларын, исәпкә алу приборларын сатып алу, хезмәт өчен шартнамә буенча түләү);
- техниканы-тракторны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү);
- ДПО ремонты

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Майна авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Майна авыл җирлеге башлыгы** **Р.Н.Гафиятуллин**